# IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ II СЕССИЯСЕ

## К А Р А Р № 13

Мөслим «13» ноябрь 2020 ел

**«Аренда түләүләрен кичектереп тору өлешендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чаралары турында» 2020 елның 17 июнендәге 185 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 14 августындагы 1536-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының «Аренда түләүләрен кичектереп тору өлешендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү чаралары турында» 2020 елның 17 июнендәге 185 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «а» пунктчасын түбәндәгечә бирергә:

«а) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары – арендаторлар, иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручылар реестрына кертелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручы – социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар мөрәҗәгать иткән көннән алып җиде эш көне эчендә, 2020 елның 1 апреленнән 2020 елның 1 октябренә кадәр түбәндәге шартларда аренда түләүләрен кичектерүне күздә тоткан өстәмә килешүләр төзүнең түбәндәге шартлары:

аренда түләве буенча бурыч арендаторлар тарафыннан билгеләнгән срокта, 2021 елның 1 гыйнварыннан да иртә түгел һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, этаплап, айга бер тапкырдан да арттырмыйча, күләме аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан артмаган тигез түләүләр белән түләнергә тиеш;

штрафлар, чит акчалардан файдаланган өчен процентлар яисә арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле рәвештә җаваплылыкның башка чаралары (шул исәптән мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда) кичектереп тору белән бәйле рәвештә кулланылмый;

кичектереп тору сәбәпле арендатор тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләр билгеләү рөхсәт ителми;

аренда килешүен вакытыннан алда өзгәндә аренда түләве буенча бурыч берьюлы түләнә;»;

«б» пунктчасында «кече һәм урта эшкуарлык субъектлары» сүзләреннән соң «, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар» сүзләрен өстәргә;

2 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

«2. Аренда түләүләрен кичектереп тору Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән көнгә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы казнасын тәшкил иткән муниципаль

мөлкәтне арендалау килешүләре буенча (шул исәптән җир кишәрлекләрен) узган чор өчен аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булмаган кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары – арендаторларга, иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручылар реестрына кертелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручы – социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга бирелә дип билгеләргә.»;

Карарны түбәндәге эчтәлекле 21 нче пункт белән тулыландырырга:

«21. 2020 елның 1 апреленә кадәр төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча җирле үзидарә органнарына, шулай ук алар карамагындагы муниципаль предприятиеләргә һәм муниципаль учреждениеләргә һәм «Яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең начараюы шартларында зыян күргән Россия икътисадының тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлыТатарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең начараюы шартларында зыян күргән Россия икътисадының тармаклары исемлеге буенча бер яки берничә тармакта эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары – арендаторлар, иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручылар реестрына кертелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручы – социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы милкендә булган күчемсез милекне арендалау килешмәләре буенча аренда түләвен кичектерерүне тәэмин итү турында»2020 елның 17 июнендәге 186 номерлы карары нигезендә, 2020 елда каралган аренда түләвен кичектерүне тәэмин итәргә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга https://muslumovo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе Р.Х. Муллин